**РЕШЕНИЕ (КАРАР)**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Субаш торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**29 октябрь 2020 г.** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 12 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, "Нагорная, Новая урамнарындагы юлларны ремонтлауга җыелган гражданнарның үзара салым акчасы 30000 сум(утыз мең сум 00 тиен) күләмендә, иске агачларны кисүгә һәм чистартуга файдалануыгыз белән килешәсезме?»

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 95 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 60 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен җыенда 60 кеше тавыш бирде;
«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлегенең Түбән Субаш авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип табылды.
2. Нагорная, Новая урамнарындагы юлларны ремонтлауга җыелган гражданнарның үзара салым акчасы 30000 сум (утыз мең сум 00 тиен), иске агачларны кисүгә һәм чистартуга файдаланырга»
3. Халык җыенының нәтиҗәләрен халыкка Югары Субаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Балтач муниципаль районы сайтында http: //baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыены рәисе
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.Б.ВАФИН